## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

2025 елның 29 ноябре №2

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (90 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:
- Күтәмәле авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

2. Күтәмәле торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү:
-Шамгун чишмәсен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү:
- Күтәмәле авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Беларусь МТЗ 82.1 тракторына (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
-Триммерга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, договор буенча хезмәтенә түләү);

5.Янгын сүндерү машинасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу),

6 .Санкциясез чүплекләрне бетерү:
- Күтәмәле авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (3 контейнер сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Имән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы Гараев Р.Ф.Гәрәев